СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Яңасала авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**15 июнь 2020 ел** **№ 48**

**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советына депутатлар сайлаулары билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясының 1 өлеше, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Уставының 13 статьясы нигезендә Яңасала авыл җирлеге Советы **карар бирде:**

1. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча “Арча хәбәрләре” (“Арский вестник”) район газетасында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда: ТР, Арча районы, Яңасала авылы, Үзәк урам, 18 йорт; ТР, Арча районы, Каенсар авылы, Урта урамы, 25 йорт, адреслары буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Яңасала авыл җирлеге башлыгы А.И. Сафин